ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

06.04.2018                    5

с. Кильдеево

2018 елгы язгы ташу чорында Килди авыл җирлеге территориясендә халыкны яклау чаралары турында

Халыкны, хуҗалык һәм торак объектларны, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне 2018 елгы язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм яклау максатларында,

Карар бирәм:

1. 5 кешедән торган язгы ташуга каршы комиссия төзергә:

Комиссия рәисе: Бурдин В. М. – Килди авыл җирлеге башлыгы,
комиссия рәисе урынбасары: Левочкина Н. Н – - Килди авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре

Комиссия әгъзалары: Мукаева Р. А. – 3 нче Килди сайлау округы депутаты
В. А. Спирин-7 нче номерлы Харин сайлау округы депутаты
Хваткова Е. А – 6 нчы Уланово сайлау округы депутаты

2. Елгаларда һәм буаларда су дәрәҗәсе өчен торак пунктларда түбәндәге җаваплы кешеләрне билгеләргә:

- Килди авылында – Кузьмичев Евгений Александрович-Килди авылында яшәүче;
– Харино авылы - Спирин Виктор Александрович-7 нче Харино сайлау округы депутаты;

3. Гражданнар җыелышларын мөлкәтне һәм корылмаларны гадәттән тыш хәлләр, ташу куркынычыннан иминиятләштерү темасына үткәрергә.

4. Килди авыл җирлеге торак пунктларында биналарның түбәләрен кардан һәм боздан чистарту эшләрен оештырырга.

5. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты алдына Килди авылының Заречная урамы буенча газүткәргечнең һава линиясен технологик юл белән тәэмин итү турында үтенечнамә бирергә.

6. Су ташу чоры тәмамлануга, кирәк булганда, бистә эчендәге юлларны,күперләрне ремонтларга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы                    В.М.Бурдин

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2018 елның
6 апрелендәге 5 номерлы карарына
1 нче кушымта

2018 елгы язгы ташу чорында Килди авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планы

| № п/п | Чара исеме | Башкаручылар | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| ОЕШТЫРУ ЧАРАЛАРЫ | | | |
| 1 | Елгаларда һәм буаларда су дәрәҗәсе өчен җаваплы Күзәтүчеләр билгеләү | Килди авыл җирлеге башлыгы | 06.04.2018 кадәр |
| 2 | Язгы ташу һәм аның үсеше турында фаразларны халыкка вакытында җиткерү | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты | 06.04.2018 - 10.04.2018 |
| 3 | Язгы ташу аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерү | Килди авыл җирлеге | ташу чорына кадәр |
| 4 | Эвакуацияләнә торган халыкны су басу зоналарыннан урнаштыру урынын билгеләү | Башкарма комитеты | 06.04.2018 кадәр |
| 5 | Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган эчә торган суның сыйфатына, ачык су чыганакларының, су алу җайланмаларының торышына санитар-эпидемиологик контрольне оештыру | Килди авыл җирлеге | ташу чорына кадәр |
| ПРАКТИК ЧАРАЛАР | | | |
| 1 | Авыл хуҗалыгы объектларын һәм биотермик чокырларны, ташкыннар белән су басуга әләгүчеләрне тикшерү | Килди авыл җирлеге башлыгы | 06.04.2018 кадәр |
| 2 | Электр белән тәэмин итү һәм элемтә кабель линияләрен, трансформатор подстанцияләрен тикшерү | Килди авыл җирлеге башлыгы , Оешма һәм предприятие җитәкчеләре, | 06.04.2018 кадәр |
| 3 | Бина түбәләрен кардан һәм боздан, елгаларны куаклардан һәм агачлардан чистарту | Оешма һәм предприятие җитәкчеләре, халык | 06.04.2018 кадәр |
| 4 | Плотиналарда су җыелуын җайга салу урыннарына керү юлларын үз вакытында | Килди авыл җирлеге башлыгы | ташу чорына кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чистарту | | |
| 5 | Килди, Харино авылларындагы плотиналарда запас суүткәргечләрне чистарту | Бурдин В.М.<br>Спирин В.А. | ташу чорына кадәр |
| 6 | Су басу вакытында азык-төлек, беренче чиратта кирәкле дарулар запасы оештырырга | Васина Л.М.<br>Бойко Т.И.<br>Камальтдинов Ш.Х.<br>Гаврилина Г.А.<br>Токсарова Г.Н. | 10.04.2018 кадәр |
| 7 | Матди-техник база белән тәэмин итү (ДТ-75 тракторы, ягулык-майлау материаллары) | Антонов Г.А. | 10.04.2018 кадәр |
| 8 | Җирлек территориясендә язгы ташуга әзерлек һәм язгы су үткәрүнең барышы турында халыкка үз вакытында хәбәр итү | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты | ташу чорында |
| КОНТРОЛЬ ЧАРАЛАР | | | |
| 1 | Язгы ташу чорына әзерлек турында оешма һәм чаралар җитәкчеләрен тыңлау. | Килди авыл җирлеге башлыгы | 10.04.2018 кадәр |
| 2 | Әлеге план буенча чараларның үтәлешен тикшерү | Килди авыл җирлеге башлыгы | 10.04.2018 кадәр |

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин